ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Балык Бистәсе авыл җирлегенең Масловка торак пунктында

Татарстан Республикасы муниципаль районы

2024 елның 15 ноябере № 13

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

– су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су бәлән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

– торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылы, Центральный урамы, 13 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А. И. Егоров

Масловка авыл җирлеге башлыгы

Балык Бистәсе муниципаль районы

Татарстан Республикасы А. И. Егоров

Совет Масловского сельского поселения Масловка авыл җирлеге Советы